**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.11.2025 № 1334

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны туклану белән тәэмин итү турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулы канлы, балансны туклану белән тәэмин итү нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, СанПиН таләпләре нигезендә 2.3/2.4.3590-20, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше нигезендә, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6 өлешендә һәм укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 07 июлендәге 689 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 172 номерлы, 2025 елның 29 июлендәге 828 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлегенең 1.1 пунктыннан түбәндәге абзацны төшереп калдырырга:

«- 4 һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдәге балаларга».

1 бүлегенең 1.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга.:

« - 3 һәм аннан күбрәк баласы булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган күпбалалы гаиләләрдән аз керемлеләр.».

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 2,3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-1-11 сыйныф укучылары өчен көнгә 77,76 сумлык кайнар иртәнге аш яки төшке аш.

Өйдә белем алучы укучылар өчен азык-төлек җыелмасы айга бер тапкыр, уку көннәре санын исәпләп, 20 нче числодан да соңга калмыйча, көнгә 77,76 сум күләмендә бирелә. Азык-төлек продуктлары җыелмасы гомуми белем бирү оешмасының күрсәтмә документында раслана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин